# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Кыркүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кыркүл авыл торак пунктында 2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

2022 елның 14 октябреннән № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Кыркүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кыркүл авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда Алексеевск муниципаль районының « Кыркүл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Кыркүл авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
- авыл эчендәге юлларны ремонтлау, төзекләндерү һәм карап тоту;
- су челтәрләрен реконструкцияләү һәм карап тоту;
- күмү урыннарын төзекләндерү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Кыркүл авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Кыркүл авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Биләр авыл җирлеге башлыгы**
**Вазыйфаларын башкаручы** **Г.Н.Бакеева**